Пыжмара гомуми урта белем мәктәбе

# Саубуллашуның хәлләре
# Таныш, һәркемгә таныш

(Бертуган Мөхәрләмовларны армия сафларына озату кичәсе)

Төзеде: 1 нче категорияле татар теле
Һәм әдәбияты укытучысы,
сыйныф җитәкчесе
Латыйпова Р.Г.

## *О З А Т У   К И Ч Ә С Е*

Саратский яшел гармун
Көмеш кыңгыраулары,
Бу көмеш кыңгырауларның
Кичке яңгыраулары
Әллә нишләтә күңелне,
Үксеп елыйсы килә...
Елау егет эшемени?!-
Эх, бер җырлыйсы килә.

*1. Кичәбезне үзенең кабатланмас моңлы тавышы белән ачып җибәрә* **Рөстәм Ахметханов.   (җыр)**

Язгы ташуларда
Аккан бозга басып,
Икәү килә елга буйлатып
Берсе җырлый шашып,
Изүләрен ачып,
Икенчесе килә уйнатып.
Сау булыгыз, кызлар,
Сагынырсыз, кызлар,
Таң атканда инде булмабыз.
Сагынсагыз әгәр
Без кайтканга кадәр
Шушы көйне отып җырлагыз,- *диләр туган ил сагына китүче егетләребез бертуган Мөхәрләмовлар. Бүген алар – бәйрәмебезнең төп хуҗалары булган асыл егетләребез – Шамил һәм Хәлил. Сәхнә түренә рәхим итегез!*

Авыл бүген егетләрне
Армиягә озата.
Ерактагы гармун  чыңы
Күңелләрне кузгата.
Егетләр гармун уйныйлар
Күрүгән тарта-тарта,
Кеше бигрәк якыная
Аерылып китәр чакта.
Күбәя әйтер сүзләр дә,
Туа яшерен сагыш
Саубуллашуның хәлләре
Таныш, һәркемгә таныш

*Туган як, туган авыл, әти-әни, туганнар һәм, әлбәттә, сөйгән ярдан аерылу хисләрен үз күңеле белән татыган, әле онытып та бетерә алмаган, солдат хезмәтеннән авыл тормышына әле яңа гына кереп баручы авылдашыбыз **Хадеев Айнурга** сүз бирәбез.*

**(Айнур сөйли.)**

**2. Җырлый Аскарова Алисә. “Әнкәй турында”**

Юллар – серле язмыш эзе, диләр,
Язмышны да узмыш булгалый.
Юлда йөрү гаять авыр, диләр,
Иң авыры солдат юллары.

Китүләр тиз, кайту озак, диләр,
Була диләр озын юллары.
Юллар якын, яки ерак, диләр,
Иң ерагы – солдат юллары.

*Сүз, сезгә озын солдат юлына чыгар алдыннан үзенең төпле киңәшләре белән хәерле юл теләп калучы җирле үзидарә рәисе **Гимадиев Мансур Сәгыйтҗан** улына бирелә.*

*(Мансур абый чыгышы)*

**3. Бии Ландыш Асхадуллина. Төрек биюе.**

“Солдат ничек яши?- дип сорыйсыз,
Аны уйлап бик сагынган вакытларда,
Мамык юрган сорап иркәләнми төнлә,
Ә көндезен походларда, окопларда.

“Солдат ничек түзә?- дип сорыйсыз,
Юка бер шинелен киеп җил-суыкта?”
Боекса да һәм туңса да – солдат җырлый,
Солдатларны җыр йөретә, җыр җылыта.

*Җырыгыз сезнең белән юлдаш булсын, җыр сезне юатсын, җыр сезне җылытсын, җыр сезне саклап йөртсен.*

**4. Җырлый туган ил сагына китүче асыл егетебез Шамил.**

Солдат, чүгеп байракка,
Ант китерә бер генә.
Яшәү кануны булып,
Кала вәгъдә гомергә.

Көч бирә мәхәббәтең,
Изге антың илеңә.
Көтә сине болын-кырларың
Кайт син туган җиреңә,
Кайт син туган илеңә.

*Туган туфрагыгыз, туган нигезегез, туган җирегез сезне һәрчак колач җәеп көтеп торачак. Туган кырлардагы һәр басу юлы, һәр башак, һәр бөртек сезнең өчен якын һәм кадерле. Чөнки сез беренче хезмәт юлыгызны шушы җирлектә башладыгыз. Сүзне “Кама” авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү кооперативы рәисе* ***Назипов Рәкыйп Нәкыйп*** *улына бирәбез.*

*( Назипов Р.Н. сөйли.)*

**5. 11 сыйныф укучылары җырлый.**

Укытучы! Мәктәп!
Бу ике сүз
Күңелләрдә һаман янәшә.
Мәктәбем!- дип әйткән чакта күңел
Укытучым!- дип йөрәк эндәшә.

*Мәктәп еллары, мәктәп юллары һәркемнең күңелендә якты хәтирәләр булып саклана. Ә менә укытучылар, мәктәп җитәкчелеге күңелендә нинди хисләр калдырды микән егетләребез? Сүзне мәктәп директоры Рахматуллин Т. В.ка бирәбез.*

*Сүз сыйныф җитәкчеләренә бирелә.*

*Егетләребезне беренче башлангыч хәрби хәзерлек серләренә төшендергән укытучылары Ахметханов Б.И.ның да аларга әйтер сүзләре бар.*

**6. Миләүшә, Рәмзия җыр**

Гаиләм – гомер юлым ул,
Сиңа сузылган кулым.
Гаиләм – малым, мөлкәтем.
Гаиләм – синле җырым

Гаиләм –таяныр ноктам,
Гаиләм - якты учак.
Гаиләм – улым, кызларым,
Гаиләм – кайнар кочак.

Без гаиләдә бәхетле,
Без гаиләдә хисле,
Без гаиләдә кадерле.
Без гаилә белән көчле!

*Гаилә ул әти-әни, энекәшләр, сеңелкәшләр, кан кардәшләр. Әйе бүген менә шушындый тулы гаиләдән берьюлы абыйлы энеле Хәлил һәм Шамилне туган ил сагына озатабыз. Егетләрне шушындый биеклеккә җиткергән Алсу апа һәм Хәбир абыйга сүз бирәбез.*

**7. Габидуллина Гөлшат “Балаларга фатиха”**

И туган җир,
Газиз әнкәм җире,
Әткәм иле, бабам туфрагы!
Җилләр кебек исеп,
Гөлләр кебек үсеп,
Кайтачакбыз сиңа без тагын, - *дип ышандырып кала безне егетләр. Сүзне егетләр сезгә бирәбез.*

Җирдә кеше булу өчен
Кеше күпме юллар үтә.
Ашкын, кешем! Сине җирдә
Еллар көтә, юллар көтә.

*Исән йөреп, сау кайтыгыз, егетләр, уң булсын юлларыгыз.*

**8. Аскарова Алисә “Сау булыгыз, ак каеннар!”**